Әлмәт муниципаль районы Башлыгы
Карары

12 май 2020 ел № 24

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 һәм 46 ст. нигезендә, Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 4 апрелендәге 234 номерлы карары белән расланган Әлмәт муниципаль районында гавами тыңлаулар уздыру турындагы Нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Әлмәт муниципаль районының Әлмәт, Аппак, Бута, Кичү, Рус Акташы авыл җирлекләре территорияләре буйлап уза торган «Яңа Елховой нефть ятмаларының өстәмә скважиналарын төзекләндерү. 7 этап» объекты өчен территорияне планлаштыру проектын һәм ызанлау проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. Гавами тыңлаулар уздыру срогы - әлеге карар басылып чыккан көннән алып кимендә бер айдан да ким һәм өч айдан да артык булмаган вакытка.
3. Гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Бута авыл җирлеге, Бута авылы, Зур ур., 1 й. адресы буенча 2020 елның 5 июнендә 15.00 сәгатьтә уздырырга.
4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай проспекты, 9А йорт, 3 каб. адресы буенча урнашкан “Әлмәт муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе” муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан 2020 елның 5 июненә кадәр территорияне ызанлау проекты һәм планлаштыру проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул ителә.
5. Бута авыл җирлеге башкарма комитетына (Абрамов Д.Е.) гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләүне һәм уздыруны тәкъдим итәргә.
6. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
7. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Муниципаль
район Башлыгы Т.Д. Нагуманов